РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ф.Хусни, 56 А, село Большие Метески,
422082
тел.: (884360) 54-4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318062 ОГРН 1021607156780

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Ф.Хөсни урамы, 56 А, Олы Мәтәскә авылы,
422082
тел.: (884360) 54 -4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ИНН/КПП 1619000590/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 4** **от 17.02.2026г**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә яшәүче гражданнарның генераль планнар проекты буенча фикер алышуда гаммәви тыңлаулар уздыру юлы белән катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2026 елның 25 февралендә «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлауларны билгеләргә.
2. Теләче муниципаль районы «Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлауларны 2026 елның 25 февралендә түбәндәге адресларда үткәрергә:

2.1. 10.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, адресы буенча: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатыйх Хөсни урамы, 56А йорт.

2.2. 11:00 сәгатьтә, Олы Мәтәскә авыл мәдәният йорты бинасында, адресы буенча: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә авылы, Үзәк урамы, 17А йорт.

2.3. 12:00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, адресы буенча: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Лесной поселогы, Татарстан урамы, 8 йорт.

2.4. 13:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Ямбулат авылы, Татарстан урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында.

2.5. 14:00 сәгатьтә, Тәмте Мәтәскә авылы, Подгорная урамы, 15 йорт адресы буенча, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы бинасында.

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты:

3.1. 2026 елның 18 февраленә кадәр әлеге карарны, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты материалларын җирле үзидарә органының мәгълүмат стендында игълан итеп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының рәсми сайтында (tulachi.tatarstan.ru), Олы Мәтәскә авыл җирлеге бүлегендә – авыл җирлегенә территориаль планлаштыру документациясе керүче бүлекчәдә урнаштырырга.

3.2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларда генераль план проектын эшләүчеләрнең («ГК-Групп» ҖЧҖ) катнашуын тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлауларны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2024 елның 1 ноябрендәге № 131 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гаммәви тыңлауларны оештыру һәм алып бару тәртибе буенча үткәрергә.

5. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 номерлы кушымта нигезендә  расларга.

6. «Татарстан Республикасы Теләче  муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем  оештырырга һәм аның составын  2 номерлы карар нигезендә расларга.

7. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы Бәяләмәне «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын раслау турында йә генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында Карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советына җибәрергә., шулай ук генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы Бәяләмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.и Теләче муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

8. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты экспозициясен үткәрү вакыты: 2026 елның 18 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр эш көннәрендә һәм вакытында, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы

Олы Мөтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты экспозициясен ачу урыны 422082, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мөтәскә авылы Фатыйх Хөсни ур., 56 йорт адресы буенча.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Теләче муниципаль районы
Олы Мөтәскә авыл җирлеге башлыгы Ш.В.Кәримуллин

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл
җирлеге башлыгының 17.02.2026 ел
4 номерлы карарына 1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге генераль планы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Башкарма комитетына 422082, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатыйх Хөсни урамы, 56 йорт адресы буенча язма формада тапшырыла.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы рәсми сайтында (tulachi.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларына, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ruInsert урнаштырылган көннән алып 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр эш көннәрендә 2026 елның 18 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр кабул ителә.

2. Гаммәви тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризаләр: 422082, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатыйх Хөсни урамы, 56 йортка шәхси рәвештә яки почта аша (конвертта “Олы Мәтәскә авыл җирлеге генераль планы буенча фикер алышу” дип күрсәтеп) тапшырыла.

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгының 17.02.2026 ел 4 номерлы карарына 2 номерлы кушымта

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемне түбәндәге составта булдырырга:

Кәримуллин Ш.В. – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгы;

Сөнгатуллин М.М. — Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы депутаты (килешеп).

Әхмәтвәлиев Ф.Ф. - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы депутаты (килешеү буенча);

Исхакова Э.М. - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең генераль планы проектын эшләүчеләр - ҖЧҖ «ГК-Групп» (килешү буенча).